СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 19-21 от «26» апреля 2023 г.

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртүне оештыру турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге № 343-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2012 елның 23 апрелендәге №13-12 карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын утильләштерү һәм эшкәртүне оештыру турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Нигезләмәнең 1 бүлегендәге 6 пунктының 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Калдыклар урнаштыру объектлары - калдыкларны, шул исәптән җир асты байлыкларыннан файдалану калдыкларын урнаштыру өчен билгеләнгән махсус җиһазландырылган корылмалар («Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-I номерлы Россия Федерациясе Законы нигезендә кулланылырга тиешле ачык һәм сыйдырышлы тау токымнарын саклау объектларыннан башка), калдыкларны саклау объектларын һәм калдыкларны күмү объектларын үз эченә ала;».

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советының әлеге карары 01.09.2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, «Интернет» мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан

000042

Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны дүртенче чакырылыш Мамадыш муниципаль районы Советының Торак-коммуналь һәм торак мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П. Иванов